**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“27” ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районың Кышлау авыл җирлеге территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Кызыл Утар авылы территориясендә үләнне чабу һәм чистарту;
- "Әшрәп" чишмәсен ремонтлау, (төзелеш материаллары сатып алу, чишмәгә кадәр төшү өчен тимер баскыч урнаштыру, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- Кызыл Утар авылы коелары өчен коймалар урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- Урам утын карауга хезмәт хакы тулəү.

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Кызыл Утар авылы зиратында куаклар кисү, үләннәр һәм үсемлекләр чабу. (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл-Утар авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.

Совет Кышлауского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы
ИНН 1610006...